РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА АМЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Әмзә ав **КАРАР**

«29» марта 2024 года № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 11 апрелендә 11 сәгать 00 минутка Иске Татар Әмзәсе авылы, К. Маркс ур., 29нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Татар Әмзәсе авыл мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Рус Әмзәсе авылында үзара салым кертү, элек расланган карарларга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены уздыруны билгеләргә

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 22.11.2023 ел, №7 карары;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 22.11.2023 ел, №8 карары.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 22.11.2023 ел, №7 карарның 1 пунктына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе авылы торак пунктында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

"Сез 2024 елда Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе авылы территориясендә яшәүче 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш  һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә

үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Рус Әмзәсе торак пунктында ВНБ территориясен коймалау).

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе торак пунктында гражданнар Җыенының 22.11.2023 ел, №8 карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп::

1. 2024 елда Әмзә авыл җирлегенең Иске Рус Әмзәсе авылы территориясендә яшәүче 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш  һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Рус Әмзәсе торак пунктында ВНБ территориясен коймалау).

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Рус Әмзәсе авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина